БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» 06 2021 ел № 199

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә акчалата түләүләрне билгеләү турында» 2020 елның 30 апрелендәге 165 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» 2020 елның 30 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә акчалата түләүләрне билгеләү турында» 2020 елның 30 апрелендәге 165 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең хезмәткәрләренә - яшь белгечләренә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүләр бирү тәртибе түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Хезмәткәр - яшь белгеч дип 35 яшькә кадәрге (35 яшьне кертеп) («Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» 2020 елның 30 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 3 өлешендә каралган очраклардан тыш), төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яисә) һөнәри белем бирү программалары буенча укуын тәмамлаган, алынган квалификация нигезендә беренче тапкыр эшкә урнашучы Россия Федерациясе граждан таныла.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы И.С. Галимуллин